БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 02 2022 ел № 71

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2022 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күләмен билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 3171564 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 4036536 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 5189832 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 6919776 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 8649720 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 10379664 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 12109608 сум;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен - 13839552 сум.

1.2. Исәпләүләр буенча гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме (1нче кушымта) тәшкил итә:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 72960,62 сум;

1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 46429,49 сум;

1.2.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 39796,70 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда, җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2022 елның _____________
__71__ номерлы карарына
кушымта

**2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү**

**МЕТОДИКАСЫ**

1. Найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече (алга таба - исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП Х РС х РЦ, биредә

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - РФ төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәп-хисап бәясе (2022 елның беренче кварталына – 96108 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 96108 х 33 = 3171564 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 42 = 4036536 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 3 = 5189832 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 4 = 6919776 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 5 = 8649720 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 6 = 10379664 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 7 = 12109608 сум

3) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 96108 х 18 х 8 = 13839552 сум

2. Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең иң чик күрсәткече:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) - КП) / (0,3 х РС), биредә

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урын алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унлы вакланма), (Россия Федерациясе Үзәк Банкы ставкасы елына 8,5%, ягъни 8,5/100/12 айга=0,0071 айга).

КП - кредитның барлык вакыты буенча кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

Торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе «2022 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2022 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 96 мең 108 сум күләмендә билгеләнгән.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечен исәпләү**

1 нче таблица

| НП - торак урынның нормасы (кв. м) | СЖ - торак урын сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (сум) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - торак урынның 1 квадрат метрының базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы | ПД - Керемнең чик күрсәткече (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 96108 | 8,5/100/12= 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,3 | |
| 33 | 3171564 | 1 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,3 | 72960,62 |
| 42 | 4036536 | 2 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,6 | 46429,49 |
| 54 | 5189832 | 3 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 0,9 | 39796,70 |
| 72 | 6919776 | 4 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,2 | 39796,70 |
| 90 | 8649720 | 5 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,5 | 39796,70 |
| 108 | 10379664 | 6 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 1,8 | 39796,70 |
| 126 | 12109608 | 7 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 2,1 | 39796,70 |
| 144 | 13839552 | 8 | 96108 | 0,0071 | 180 | 0,7 | 2,4 | 39796,70 |